**СОВЕТ**
**Кичкетанского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кичкетан авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.08.2024 Кичкетаң авылы № 44-1

Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге Советының "Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында" 02.07.2024 елның 43-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге Советының "Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында" 02.07.2024 елның 43-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктның 5 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 2 пунктның 5 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының веб-адрес буенча хокукый мәгълүматның рәсми порталында хәбәр итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы И.Н.Җиһангәрәев